МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

2019 № 137

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле булган һәм билгеләнгәндә дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

2004 ел 27 нче июль № 79-ФЗ «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» Федераль законның 22 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы (алга таба – Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы) структурасын һәм штат расписаниесен үзгәртүгә бәйле рәвештә б о е р ы к б и р ә м :

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле булган һәм билгеләнгәндә дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2016 ел 23 нче май № 214 «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче

белешмәләрне файдалануга бәйле булган һәм билгеләнгәндә дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында»гы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерыкны министр урынбасарларына, эшләр белән идарә итүче, Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы аппаратының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә җиткерергә.

4. Биредәге Боерыкны үтәү контролен үземә калдырам.

Министр вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Н.В. Суржко

09.04.__2019 № 137_
Татарстан Республикасы
ГТХМ боерыгы белән
расланган

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне файдалануга бәйле булган һәм билгеләнгәндә дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрмәскә мөмкин булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге**

1. Министрның беренче урынбасары
2. Министр урынбасары
3. Эшләр идарәчесе
4. Финанс-икътисад идарәсе башлыгы
5. Табигать һәм техноген куркынычсызлык бүлеге башлыгы
6. Геомәгълүмат системалары бүлеге башлыгы
7. Гражданлык оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне тормышка ашыру бүлеге башлыгы
8. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы
9. Эшчәнлекне планлаштыру бүлеге башлыгы
10. Мәгълүмат бүлеге башлыгы
11. Мәгълүмат коммуникацияләре технологияләре һәм мәгълүматны яклау бүлеге башлыгы
12. Хәбәр итү һәм элемтә башлыгы
13. Хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы
14. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы
15. Вазыйфаи затларны һәм халыкны әзерләү бүлеге башлыгы
16. Авария-коткару формированиеләрен булдыру, аттестацияләү һәм теркәү бүлеге башлыгы
17. Гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең төп киңәшчесе
18. Гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең төп консультанты
19. Гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече
20. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегенең төп киңәшчесе (коррупциягә каршы эшчәнлек буенча)